Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№4 (65) Гыйнвар, 2025 нче ел



*«Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк»*

*Шиһабетдин Мәрҗани*

Бу санда


Мин яңа елдан нәрсә көтәм? 2

Башкалар кебек буласым килә 2

Театр дөньясында 2

Кулга каләм алгач... 3

Яшь каләм тибрәтүчеләргә киңәшләр 4

Укучылар иҗаты 4

Ял сәгатьләрендә 4


## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### 2025 ел — Ватанны саклаучылар елы




Россия Президенты Владимир Путин 2025 ел - Ватанны саклаучылар елы дип игълан итте. Бу карар Бөек Ватан сугышында җиңүгә 80 ел тулу уңаеннан, махсус хәрби операциядә катнашучылар хөрмәтенә һәм төрле тарихи чорларда Ватан өчен көрәшкән барлык ата-бабаларыбызның батырлыклары истәлегенә кабул ителде.

«Киләсе елда без Бөек Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтәчәкбез. Шуңа бәйле рәвештә 2025 елны Ватанны саклаучылар елы дип игълан итәргә тәкъдим итәм. Безнең геройлар һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар хөрмәтенә һәм Ватаныбыз өчен төрле тарихи чорларда сугышкан ата-бабаларыбызның батырлыклары истәлегенә. Нацизмны җиңгән әтиләребез, бабаларыбыз, бабаларыбыз даны өчен", - диде Владимир Путин.

Татарстанда да 2025 нче ел Ватанны саклаучылар елы дип игълан ителде.

«Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», – дип язган бөек галимебез Шиһабетдин Мәрҗани. Тарихи хәтерне саклау – киләчәк буыннар алдындагы бурычыбыз. Бу безгә буыннар бәйләнешен тирәнтен тояргa, киләчәккә ышаныч белән карарга ярдәм итә», – диде Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов.

### Фән олимпиадалары старт алды







Республикада фән олимпиадаларының Республика турлары башланып китте. Укучылар өчен уздырыла торган фән олимпиадаларының рәсәй һәм республикакүләм турында Мөслим гимназиясе укучылары да катнаша. Математика фәненнән «Олимпка юл» республикакүләм укучылар олимпиадасында 10 нчы сыйныф укучысы **Дәүләтшин Әмир** призлы урынга лаек булды. Укытучысы - Госсамова Рамиля Сабирҗан кызы. 8 нче а сыйныфы укучысы **Хафизова Әминә** физкультура фәненнән призер. Укытучысы – Шәйхетдинов Дамир Гәйнетдин улы.

10 нчы сыйныф укучысы **Габидуллина Азалия**, 11 а нче сыйныфы укучысы **Ханнанова Адилә** рус теленнән Россиякүләм предмет олимпиадасының регион этабында призерлар булдылар. Укучыларны олимпиадага Хәйруллина Чулпан Алмаз кызы һәм Галиева Ирина Тимерхан кызы әзерләде.

Укучыларны һәм укытучыларны зур уңышлары белән котлыйбыз!!!

## МИН ЯҢА ЕЛДАН НӘРСӘ КӨТӘМ?




Яңа 2025 нче ел башланып китте. Анда безне нәрсә көтүе турында фаразлау бик авыр. Элек мин һәрчак алда нәрсә булачагын һәм нәрсәгә әзерләнергә кирәген беләм дип уйлый идем. Әмма узып баручы ел барысы да бездән генә тормавын раслады.

Мин киләсе елдан ни көтәм соң? Иң мөһиме, әлбәттә, сугышларның тәмамлануы. Боларның барысы да тәгәлләнгәннән соң яңадан планнар корып, яхшыга өметләнеп булачак бит. Дөнья тыныч булганда гына кешеләр күңеле тыныч.

Кешеләр Яңа елдан тагын нәрсә көтә? Әлбәттә, шатлык һәм яхшылык. Һәр кеше кебек үк мин дә бары тик яхшылык кына көтәм. Узган ел бөтен дөнья өчен авыр булды, шуңа күрә күпмедер дәрәҗәдә без берләшкәнбездер. Яңа елда барыбыз да исән-сау булсак, шатлансак, якыннарыбызны югалтмасак иде һәм без моңа ирешербез дип өметләнәм. Җәен дә, кышын да барыбыз да урамга чыгуыбызны, киләсе елга күбрәк театрларга йөрүебезне, спектакль-кинолар каравыбызны телим. Иң мөһиме, сәламәт булыйк. Барысы да исән һәм сәламәт булса, бөтен хыяллар да чынга ашачак.

Менә шундый минем хыялларым: гади, «җир» хыяллары. Килешәсездер, мин бит күп теләмим. Хәер, юк, әлбәттә, бу бик күп! Чөнки минем теләкләремнең күбесен акчага сатып алып булмый...

Ә сез яңа елданниләр көтәсез?

***Зәкиева Әминә,***
***8 нче в сыйныфы укучысы***



### Театр дөньясында

Театр - милләтебезнең иң яраткан сәнгать төре. Күренекле драматург Туфан абый Миңнуллин да: "Театрны татар кебек яраткан халык юк" дип дөрес бәя биргән. Хәтта русның бөек язучысы В.Г.Белинский да: "Татарлар бик теләп театрга йөриләр һәм аны бик яраталар икән" дип язып калдырган. Әйе, без театрлы халык, татар театры яшәргә тиеш!

Гимназиянең "Яшь театр сөючеләр" түгәрәгенә йөрүче 2 нче б сыйныфы укучылары Фирдәвес Әһлиянең "Туган тел ачкычы" исемле спектаклен сәхнәләштерделәр. Балаларны түгәрәк җитәкчесе Фәхертдинова Ләйсән Әхмәтгаяновна әзерләде. Аңа зур рәхмәтебезне белдерәбез, иҗат уңышларының беркайчан да саекмавын телибез.

## БАШКАЛАР КЕБЕК БУЛАСЫМ КИЛӘ



***1. Синең буш вакытың бармы?***

"Буш вакыт" – түгәрәкләр вакыты да, төшке яки кичке аш вакыты да түгел. Бу – ни теләсәң, шуны эшли торган вакыт.

Син үз вакытыңны үзең дөрес планлаштыра ала торган яшьтә. Әти-әниең белән киңәшләшеп, мәктәп, дәрес әзерләү, өйдә булышу, ашау, йокы һәм буш вакыт та кергән көндәлек план төзегез.

***2. Сыйныфташларың сиңа карата нинди мөнәсәбәттә?***

Синең яшьтә дуслар булу мөһим. Бәлки, сыйныфташларың белән сөйләшергә уртак темалар, кызыксынулар булмау синдә ялгызлык хисе уятадыр?

Шулай булса, сыйныф җитәкчегез яки әти-әниләрнең ярдәме кирәк булачак. Сыйныфыгыз белән бергәләп төрле осталарханәләргә барыгыз. Бу һәркайсыгызның сәләтен ачарга. Берләшергә ярдәм итәр. Ә менә укуда артта калучы сыйныфташларыңа үзең дә ярдәм итә аласың!

***3. "Отличник" дип, укытучылар, әти-әниең сиңа артык зур таләпләр куймыймы?***

Бар яктан да алдынгы булу бик күп энергия таләп итә. "Нишләргә

***<u>Психолог янында</u>***

соң?" – диярсең. Кайвакыт идеаль булмаска! Мәсәлән, яхшы укымасаң, нишләр идең – шул турыда хыялланып кара. Хыяллану – шуны эшләү диген сүз түгел бит әле! Ә менә шул хыялларың сиңа нәрсә җитмәвен күрсәтер.

Әйтик, мәктәпкә бөтенләй барып тормаска идем, дип хыялландың, ди. Ә бу вакытта нәрсә белән шөгыльләнер идең? Урамда йөрер яки телевизор карар, телефонда "утырыр" идем, дип җавап бирүең бар. Димәк, синең гадәти көннәрдә моны эшләргә вакытың калмый. Тизрәк беренче сорауга әйләнеп кайт һәм вакытыңны дөрес планлаштырырга өйрән! Уңышлар сиңа, дустым!

***Гимназия психологы***
***Кашапова А.Т. киңәшләрен***
***Имаева Алинә тыңлады.***

## КУЛГА КАЛӘМ АЛГАЧ...

### Ял көне



Без ял көнен гаилә белән бик күңелле үткәрәбез. Иртән тору белән, әни безне үзе пешергән тәмле ризыклары белән сыйлый. Аннан әнигә, әтигә булышам. Һәр кеше үз эшен башкара. Өйдә эшләр беткәч, авылга әби янына кайтабыз. Кайтканда, табигатьнең матурлыгына сокланып кайтабыз. Туктап ял да итеп алабыз. Ял сизелмичә, рәхәт үтеп китә.

***Мирхаҗиянова Ясминә***

### Ял көннәрен ничек үткәрәм



Ял көннәрен һәр кеше көтеп ала. Без дә гаиләбез белән түземсезләнеп ялларны көтәбез. Буш вакытымда әнигә өй җыештырырга булышам, музыка тыңлыйм, телевизор карыйм.

Җәен без гаиләбез белән су коенабыз, урманга барабыз, велосипедта йөрибез, сәяхәт итәбез. Кышын чаңгыда, тимераякта шуабыз.

Ял көннәрен күңелле һәм файдалы үткәрәбез.

***Петров Данир***

***Мөслим гимназиясенең 3 нче а сыйныфы укучылары иҗаты***

### Әтием

Әтиемне яратканга күрәдер, минем беренче сүзем дә “әттә” булган. Әтием минем уңган, ачык күңелле, ярдәмчел. Нинди генә эшкә тотынса да, булдыра. Аның исеме Илфар. Ул "МСО” да балта остасы булып эшли. Үз эшен ярата һәм кирәк чакта миңа үзенең киңәшләрен бирә, ярдәм итә. Эшемне башкарганда авырлыклар килсә, ул миңа “син булдырасың!” ди. Кыенлыклар килсә, бирешмәскә өйрәтә. Әтием минем өчен үрнәк, мин аны яратам.

***Хөсәинов Айзат***

### Минем мәктәп укучысы буларак ял көнем



Күпчелек очракта укучы шимбә көнне ким дигәндә 2-3 дәрес укый, шуңа күрә, атнада бер генә ял көне бар. Башка көннәрдә мин дәресләргә йөрим, өй эшләрен башкарам, бүлмәмне җыештырам, рәсем дәресенә һәм бассейнга барам. Мин һәрвакытта да мәктәп биремнәрен атна дәвамында, кич белән тәмамларга тырышам, якшәмбегә өй эшләрен калдырмыйм.

Якшәмбе минем яраткан көнем, чөнки озаграк йоклый алам. Әни бу көнне һәрвакыт тәмле ризыклар пешерә.

Якшәмбе көнне каядыр барам. Әбиемнең хәлен белеп киләм, яки әби-бабайга кунакка барам. Әгәр дә туганнарымның берсенә дә кунакка бармыйм икән, мин дусларым белән паркта уйныйм.

Кызганыч, ял көне бер генә һәм ул бик тиз уза.

***Хабиров Данияр***

### Безнең гаилә



Минем гаилә дүрт кешедән тора: әтием Азат, әнием Дилбәр, апам Кадрия һәм мин – Мәрьям. Без матур, зур өйдә яшибез. Әтием энергетик, әнием шәфкать туташы булып эшли. Апам Кадрия Мөслим гимназиясенең алтынчы сыйныфында белем ала, ә мин өченче сыйныфта укыйм. Укудан тыш апам театр, мин бию һәм рәсем ясау түгәрәкләренә йөрибез.

Без күңелле итеп ял итәргә яратабыз. Җәй көннәрендә су буенда балык тотып, уйнап, йөзеп күңел ачабыз, кыш көннәрендә чана шуып, кар бабай ясап шаярабыз. Кичләрен бөтен гаилә җыелгач, утырып кичке аш ашыйбыз һәм бергәләшеп кино карыйбыз. Без тату гаилә һәм бик матур яшибез!

***Шабаева Мәрьям***



***Петрова Ралина***



***Гизетдинов Самат***

## ЯШЬ КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘРГӘ КИҢӘШЛӘР



***Сине нинди дә булса табигать күренеше таң калдырдымы? Гадәттән тыш хәл игътибарыңны җәлеп иттеме? Берәр әңгәмә вакытында яңа уйлар тудымы? Һәм синдә бу кичерешләрне сүзләргә төреп, башкаларга җиткерү теләге уяндымы?***

Ничек бу эшкә тотынырга соң? Нәрсәдән башларга? Язу осталарының берничә киңәшен генә тыңласаң да, язмаларың күпкә җанлырак, тирәнрәк, кызыклырак булыр.

Нәрсәнедер тасвирларга телисең икән, аны башта ачык итеп күз алдына китер. Син ул вакыйганы бөтен төсләре, тавышлары, вак кына детальләренә кадәр, кино караган кебек, экранда күрергә тиеш.

Үзең ничек күрәсең, ничек ишетәсең, шулай сурәтлә. Тукай күзләре үткен, күзәтүчән, билгеле, ләкин тагын бер кешенең дөньяга шул ук күзләр белән каравы беркемгә дә кирәкми.

Образлы сүзләр тап, чагыштырулар куллан. Мәсәлән, күк күкрәвен Чехов өй түбәсеннән яланаяклы малай йөгереп узу белән чагыштыра.

Бу язмаң белән нәрсә әйтергә теләвеңне ачыкла.

Язучы, телиме ул, теләмиме, әсәрләрендә үзенең эчке дөньясын чагылдыра. Шулай булгач, яхшы әсәр язар өчен, үзеңне яхшыртырга омтыл, эчке дөньяңны баетырга тырыш. Моның өчен күп күрергә, күп ишетергә, күп уйларга, күп укырга кирәк.

Тема каян алырга соң? Бер тема һәрвакыт синең өеңдә. Кешенең тормышында шулкадәр вакыйга була, алар бер китапка гына да сыеп бетмәскә мөмкин. Әби-бабайларың, әтиәниең исән чакта алар белән сөйләшеп, язмышларын белеп кал, азактан үкенерлек булмасын.

### *Укучылар иҗаты*

### Хыялларым

*Энҗе сыман көмеш таҗлар*
*Уйный-оча шаян җилдә.*
*Бөтерелә-бөтерелә*
*Таралалар тирә-юньгә.*

*Канатларын җилпи-җилпи,*
*Гуя, язда кошлар кайта...*
*Бакчадагы көч-дәрт белән,*
*Хыялларым чәчәк ата.*

### Быелгы кыш

*Тышта салкын, ләкин безгә*
*Салкын түгел,*
*Чөнки безнең күңелебез*
*Салпы түгел.*

*Чаңгычылар җилләр белән*
*Узышалар,*
*Искән җилне уздырмаска*
*Тырышалар.*

***Дәүләтшина Адилә,***
***8 нче в сыйныфы укучысы***

## ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

### Мәкальләрнең дәвамын тап

| | |
|---|---|
| Кем эшләми, ... | үз капкаңны кагарлар. |
| Берәү туеп, сикерә, ... | ун тиенлек зыян. |
| татлы булсаң, балдай бул. | ата-анаңны ташлама. |
| Ачтан үлсәң дә, ... | Ачы булсаң, тоздай бул, ... |
| Какма кеше капкасын, ... | берәү туңып сикерә. |
| Бер тиенлек куян, ... | шул ашамый. |

### *Син беләсеңме?*



ТЫЛСЫМ+
Гыйнвар,
2025 нче ел
№4 (65)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Замалова Зәринә
**Корректорлар:** Хәйруллина Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям
Фәхрәзиева Алинә
**Дизайнер:** Мостафина Рәйлә
**Компьютерда җыючылар:** Вагыйзов Айзат
Сәләмов Наил

***2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә***

**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100